ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 29.12.2023 2133 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районының жирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл буе полосаларын билгеләү яки билгеләр кую хакында гражданнарга мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районының жирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл буе полосаларын билгеләү яки билгеләр кую хакында гражданнарга мәгълүмат бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Житәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Башкарма
комитетының
29.12.2023 2133
карарына 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл буе полосаларын билгеләү яки билгеләр кую хакында гражданнарга мәгълүмат бирү ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Алабуга муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл буе полосаларын билгеләү яки билгеләр кую хакында гражданнарга мәгълүмат бирү тәртибе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әлеге юнәлештә барлык транспорт чараларына керүне, транспорт чараларының тукталуын яисә тукталыш ясавын тыя торган, яки юл яисә бер яклы хәрәкәт белән юлны яисә машина йөри торган өлешен, юлга яки юл өлешенә чыгуны тыючы билгеләр турында мәгълүмат бирү, күрсәтелгән юлларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында эшләнде.

2. Әлеге Тәртипнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

гражданнарның, юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормышын, сәламәтлеген һәм мөлкәтен саклау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү, Алабуга муниципаль районы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында алардан килгән зыяннарның авырлыгын киметү юлы белән җәмгыять мәнфәгатьләрен яклау.

3. Гражданнарга әлеге юнәлештә барлык транспорт чараларына керүне, транспорт чараларының тукталуын (3.1 юл билгесе), яисә тукталыш ясавын (3.27, 3.28, 3.29, 3.30 юл билгеләре) тыя торган һәм юл яисә бер яклы хәрәкәт белән юлны яисә машина йөри торган өлешне, юлга яки юл өлешенә чыгуны тыючы ( 5.5, 5.7.1, 5.7.2 юл билгеләре) билгеләр турында, шулай ук Алабуга муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл буе полосаларын билгеләү яки билгеләр кую хакында карар кабул итү сәбәпләре турында, юл билгеләрен (РФ Хөкүмәтенең «Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында» 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карары белән

расланган) урнаштырганчы һәм юл буе полосалары тамгаларын егерме көннән дә соңга калмыйча гражданнарга мәгълүмат бирү.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән срокларда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

- мәгълүматны Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру;

- мәгълүматны «Новая Кама» газетасында бастырып чыгару.

5. Гражданнарга юл билгесе урнаштыру яки тамгалар кую турында мәгълүмат бирүгә ярдәм итүче башка өстәмә чыганаклар кулланылырга мөмкин.